**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"30" март 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы "2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшэр торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

"2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту өчен лампалар, автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү).
2. Авыл территориясен төзекләндерү (территорияне төзекләндерү (үлән чапкыч сатып алу(1 шт.),үләннәрне чабу, агачларны кисү, чистарту) хезмәтләр өчен түләү).
3. Коелар төзү, ремонтлау һәм аларның территориясен төзекләндерү (Октябрь урамындагы (3шт.), Х.Такташ урамындагы (1шт.) коеларның әйләнәсен әйләндереп алу (материаллар сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү)).
4. Җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (Фрунзе урамындагы чишмә әйләнәсен әйләндереп алу (1шт.) (материаллар сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү)).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы Рахимзянова Г.И.